КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Республиканское агентство по печати и массовым коммуникациям**
Декабристов ул., 2, г. Казань, 420066
Тел.: (843) 570-31-22, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.tatarstan.ru
e-mail: ra.tatmedia@ tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
**Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы**
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066
Тел.: (843) 570-31-22, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.tatarstan.ru
e-mail: ra.tatmedia@ tatar.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«28» марта 2019 г. № 33-п

**Журналистларның “Многоликая Россия” XII гомумроссия конкурсы турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган “2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында БОЕРЫК БИРӘМ:

1. 2019 елда Журналистларның “Многоликая Россия” XII гомумроссия конкурсын оештырырга һәм үткәрергә.
2. 2019 елда Журналистларның “Многоликая Россия” XII гомумроссия конкурсын үткәрү турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Ф. Әхмәтовага йөкләргә.

Житәкче вазыйфаларын башкаручы,
беренче урынбасар Э.Ф. Әхмәтова

“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең
2019 елның «28» март
33-р номерлы күрсәтмәсе белән

РАСЛАНДЫ

**2019 елда журналистларның**
**“Многоликая Россия” XII гомумроссия конкурсын үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. “Многоликая Россия” XII гомумроссия конкурсы (алга таба – Конкурс) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган “2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелә.

1.2. Конкурсның гамәлгә куючысы/оештыручысы – Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык (Россия ФАДН) һәм “Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясы” региональ иҗтимагый оешмасы ярдәме белән, “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Агентлык) ;

1.3. Конкурс турында мәгълүмат Агентлыкның рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) “Яңалыклар”, “Конкурслар” бүлекләрендә урнаштырыла.

1.4. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар һәм акчалата бүләкләр тапшырыла;

1.5. Конкурска бер генә гариза керсә һәм/яисә бер гариза да кермәсә, Конкурс үткәрелмәде дип таныла.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максаты – массакүләм мәгълүмат чараларында журналистларның күпмилләтле Россия халыклары тормышын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, халыкларның этно-мәдәни үсеше һәм хезмәттәшлеге мәсьәләләрен яктыртучы һәм мәдәни үсешкә, мәдәни мирасны саклап калуга, халыклар арасындагы һәм диннәр арасындагы татулыкны һәм бердәмлекне саклауга, гомумгражданлык җәмгыятен ныгытуга, шулай ук яшь буында милли мәдәниятләргә, традицияләргә һәм гореф-гадәтләргә ихтирам тәрбияләүгә зур өлеш керткән аеруча әһәмиятле һәм талантлы эшләрен ачыклау һәм бүләкләү.

2.2. Конкурсның төп бурычлары:
– җәмгыятьтә милләтара мөнәсәбәтләр һәм татулык культурасын булдыру;
– әхлакый-этик һәм гражданлык-патриотик хисләр, тарихи мирасны, туган якның традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен сәнгати-эстетик кабул итүне тәрбияләү;
– массакүләм мәгълүмат чараларында күпмилләтле җәмгыятьтә мәдәниятләр, традицияләр һәм гореф-гадәтләр төрлелеген, мәдәниара һәм динара мөнәсәбәтләрнең һәм хезмәттәшлекнең уңай мисалларын яктыртуны стимуллаштыру.

## 3. Конкурсның номинацияләре

3.1. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

- “Телесюжетлар циклы”
- “Телепроект (документаль фильм, телепрограммалар циклы)”
- “Радиотапшырулар (репортажлар) циклы”
- “Басма мәгълүмат чараларында язмалар циклы”
- “Интернет массакүләм мәгълүмат чараларында материаллар циклы”
- “Массакүләм мәгълүмат чараларында балалар-яшүсмерләр өчен проектлар”

## 4. Конкурста катнашучылар

4.1. Конкурста журналистлар коллективлары (законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән Россия Федерациясе массакүләм мәгълүмат чаралары) катнаша.

4.2. Конкурска гариза бирүчеләр – Конкурс турында нигезләмәнең 5.2. пункты нигезендә документлар тапшырган журналистлар коллективлары (законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре).

4.3. Конкурста катнашучылар – тапшырылган эшләре Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән журналистлар коллективлары (законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән ММЧ редакцияләре).

4.4. Гариза бирүчеләр Конкурста катнашу өчен әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә бәян ителгән тәртиптә һәм күрсәтелгән шартларны, таләпләрне үтәп документлар әзерләргә һәм тапшырырга тиеш.

4.5. Конкурска җибәрелгән эшләр ике яки аннан күбрәк редакция тарафыннан башкарылган булырга мөмкин.

4.6. Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен җаваплылык эшләрне тәкъдим иткән катнашучыларга йөкләнә.

4.7. Гариза бирүче Конкурсның бер номинациясендә катнашу өчен бер генә гариза бирә ала.

4.8. Конкурска гариза бирүче берничә номинация буенча документлар тапшыра ала, бу очракта жюри тарафыннан карала торган документлар һәрбер

номинация буенча аерым әзерләнергә тиеш. Бер конкурс эше төрле номинацияләргә тапшырыла алмый.

## 5. Конкурсны үткәрү шартлары

5.1. Конкурска массакүләм мәгълүмат чараларында 2018 елның 1 августыннан 2019 елның 1 августына кадәрге чорда чыккан эшләр кабул ителә;

5.2. Агентлык Конкурска түбәндәге документларны кабул итә:

- катнашу өчен Анкета-гариза (1 нче кушымта), әлеге документ эшләрне конкурсантлар исемлегенә кертү өчен төп документ булып тора;

- түбәндәге конкурс эшләре (кимендә 3 һәм иң күбе 10 эштән торган эшләр циклы):

- MP4 форматындагы CD яисә DVD дискларда (флешкартада) телевизион эшләр (программалар, махсус репортажлар, видеосюжетлар циклы, документаль фильм). Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе мөһере (булган очракта) һәм җитәкчесе имзасы белән таныкланган булырга тиеш;
- басма массакүләм мәгълүмат чараларындагы язмалар (язмалар сериясе, махсус чыгарылышлар), төп нөсхә яки күчермә нөсхә рәвешендә/сканер аша чыгарылган вариантта. Язмалар массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе мөһере белән (булган очракта) һәм җитәкчесе имзасы белән таныкланган булырга тиеш;
- Интернет басмалардагы язмалар, адреслы сылтама күрсәтелеп, кәгазь вариантта булырга, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе мөһере белән (булган очракта) һәм җитәкчесе имзасы белән таныкланган булырга тиеш;
- MP3 форматындагы CD яисә DVD дискларда (флешкартада) радиоэшләр (программалар, махсус репортажлар, радиосюжетлар циклы). Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе мөһере (булган очракта) һәм җитәкчесе имзасы белән таныкланган булырга тиеш.

- Түбәндәге гамәлгә кую документлары (документларны сканер аша чыгарылган PDF-файл форматында тапшыру рөхсәт ителә):

1) юридик зат буларак теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН) (күчермәсе);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләп кую турында боерык (күчермәсе);

гамәлгә кую документлары (күчермәләре);

ММЧ теркәү турында таныклык (күчермәсе) – массакүләм мәгълүмат чаралары өчен;

2) юридик зат булмаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык (күчермәсе);

массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе уставы яисә, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясендә кимендә 10 кеше эшләсә, “Массакүләм мәгълүмат чаралары турында” 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – ММЧ турында Закон) 20 статьясы нигезендә аны алмаштыра торган шартнамә;

3) уртак эшләрне тәкъдим итә торган ММЧ редакцияләре өчен:

- конкурс эшенә призлы урын бирелгән очракта акчаны процентлап бүлешү турында килешү.

5.3. Конкурс эшләре Россия Федерациясе дәүләт телендә, Россия Федерациясе республикалары дәүләт телләрендә, Россия Федерациясендәге башка халыклар телләрендә тапшырыла. Россия Федерациясе дәүләт телендә булмаган эшләрнең русчага тәрҗемәсе бирелә. Ул массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе мөһере (булган очракта) һәм җитәкчесе имзасы белән таныкланган булырга тиеш.

5.4. Конкурска килгән эшләргә рецензия бирелми.

5.5. **Документлар 2019 елның 1 августына кадәр (әлеге датаны да кертеп)** “Татмедиа” матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы тарафыннан алынырга тиеш. Документларны җибәрү өчен адрес: 420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, 6 кат, 5 кабинет, ММЧ бүлеге, “Многоликая Россия” конкурсына. Тел.: 8(843)570-31-12, e-mail: mnogolikaya2018@mail.ru.

5.6. Конкурска документлар почта элемтәсе аша яисә китереп тапшырыла.

5.7. Документларның Агентлыкка кергән көне аларны тапшыру датасы булып исәпләнә.

5.8. Анкета-гаризаны һәм конкурс эшен билгеләнгән срокны бозып тапшыру, анкета-гаризаның/конкурс эшенең булмавы, анкета-гаризаның/конкурс эшенең әлеге Нигезләмәгә туры килмәве, сурәтендә яисә тавышында хилафлыклар булган эшләрне тәкъдим итү Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигез булып тора.

5.9. Конкурска кертелмәгән эшләр, җитешсезлекләре бетерелеп, документлар тапшыру өчен билгеләнгән срокларда яңадан Конкурска тәкъдим ителергә мөмкин.

5.10. 2019 елның 1 августыннан соң алынган конкурс эшләре Оештыру комитеты тарафыннан каралмый.

5.11. Конкурска йомгак 2019 елның октябреннән соңга калмыйча ясала һәм беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Җиңүчеләрне бүләкләү датасы өстәмә рәвештә хәбәр ителә.

5.12. Конкурсны оештыручы эшләрне, шул исәптән бүләкләргә лаек булган эшләрне дә киләчәктә файдалануны күздә тотмый, шуңа бәйле рәвештә конкурста катнашучылар эшләрне киләчәктә ничек файдалануны мөстәкыйль хәл итә. Бу авторга иҗади эштән үзе теләгәнчә файдаланырга, аерым алганда, килешү төзерлек зат яисә оешма табу мөмкинлеген бирә.

5.13. Конкурс шартлары буенча, тәкъдим ителгән эшләрне катнашучыларга/гариза бирүчеләргә кире кайтару, конкурста катнашучының/гариза бирүченең эшне кире кайтару турындагы таләбе буенча гына, мондый таләп алынган мизгелдән алып 20 (егерме) календарь көн дәвамында аның исәбеннән гамәлгә ашырыла.

5.14. Катнашучыга Конкурска кертелмәү турында хәбәр документларны алган мизгелдән алып 3 эш көне дәвамында Оештыручы җитәкчесе/җитәкче урынбасары имзалаган һәм анкета-гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы рәсми хат белән хәбәр ителә.

5.15. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һ.б.) катнашучы тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

## 6. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

6.1. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары:
- материалның темага туры килүе (0-5 балл);
- эчтәлекнең Конкурс тематикасын чагылдыруы (0-5 балл);
- башкару осталыгы (0-5 балл);
- эшләрнең иҗади булуы (0-5 балл);
- тематиканы яктыртуның кабатланмаган һәм тапталмаган булуы (0-5 балл).

6.2. Баллар суммасының призлы урыннарга туры килүе:
1 урын: – 25-21 балл;
2 урын: – 20-16 балл;
3 урын: – 15-11 балл.

6.3. Эшләр циклы циклдагы эшләрнең барысын да күздә тотып карала.

## 7. Конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе

7.1. Конкурс комиссиясе Конкурсны оештыручы приказы белән 13 кеше составында раслана һәм рәистән, рәис урынбасарыннан һәм комиссия әгъзаларыннан төзелә.

7.2. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез башкара.

7.3. Конкурс комиссиясенең эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Утырышта комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип таныла.

7.4. Конкурс эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары аның тарафыннан билгеләнгән урынбасарына йөкләнә.

7.5. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурска тапшырылган эшләрне әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән Конкурс эшләрен бәяләү критерийлар нигезендә бәяли. Һәрбер критерий буенча балларның саны 5 баллы шкала (0 – 5 балл) буенча бәйләнә. Конкурс эше тиешле номинациягә тапшырылмаган булса,

конкурс комиссиясе бу конкурс эшен аңа туры килә торган номинациядә карау хокукына ия.

7.6. Конкурска гариза бирүче эшен тапшырганда Конкурс номинациясен дөрес билгели алмаган очракта, Конкурс комиссиясе Конкурс эшенә туры килә торган номинацияне мөстәкыйль билгели.

7.7. Бер номинациягә бер генә гариза тапшырылса, бер гариза да тапшырылмаса, тапшырылган гаризаларның берсе дә конкурс шартларына туры килмәсә, катнашкан эшләрнең берсе дә билгеләп үтәргә лаек дип танылмаса, Конкурс бу номинациядә үткәрелмәгән дип таныла һәм акчалар билгеләнгән башка җиңүчеләр арасында, Гран-придан тыш, тигез итеп бүленә.

7.8. Баллар тигез булганда Конкурс комиссиясе әгъзалары карары нигезендә призлы урыннар ике яисә берничә җиңүчегә бирелергә мөмкин, бу очракта әлеге призлы урынга тәгаенләнгән акчалар җиңүчеләр арасында тигез өлешләп бүленә һәм җиңүчеләрнең һәрберсенә бер призлы урын бирелә.

7.9.Җиңгән эш берничә авторныкы (физик затлар өчен)/берничә ММЧ (юридик затлар өчен) булса, ул эшне башкаруда катнашкан затлар арасында үзләре килешенгән күләмдә бүленә. Мондый килешү әлеге Нигезләмәнең 5.2 пункты нигезендә документлар белән бергә тапшырыла.

7.10. Конкурс комиссиясе конкурста җиңүчеләрне Нигезләмәгә таянып билгели.

7.11. Конкурсны оештыручы оештыру-техник эшчәнлекне җайга салу, утырышны әзерләү һәм конкурс комиссиясе документациясен алып бару өчен җаваплы секретарь билгеләп куя.

7.12. Җаваплы секретарь конкурс комиссиясе составына керми һәм утырышларда тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

## 8. Финанс белән тәэмин итү

8.1.Конкурсны үткәрү чаралары, шул исәптән җиңүчеләрне бүләкләү вакытында туклану һәм яшәү чыгымнары Татарстан Республикасы бюджетыннан Программага бүлеп бирелгән акчалар исәбенә финанслана.

8.2. Конкурсның гомуми приз фонды 1 820 000 сум тәшкил итә.

8.3. 500 000 күләмендәге төп приз – “Гран-при” конкурста катнашкан эше барлык номинацияләр арасында иң күп балл җыйган катнашучыга конкурс комиссиясенең тавыш бирү юлы белән бирелә, баллар саны тигез булган очракта, Конкурс рәисе тавышы хәлиткеч булып санала.

8.4. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

**“Телесюжетлар циклы”**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 70 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**“Телепроект (документаль фильм, телепрограммалар циклы)”**

1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 70 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**“Радиотапшырулар (репортажлар) циклы)”**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 70 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**“Басма мәгълүмат чараларында язмалар циклы”**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 70 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**“Интернет массакүләм мәгълүмат чараларында материаллар циклы”**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 70 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**“Массакүләм мәгълүмат чараларында балалар-яшүсмерләр өчен проектлар”**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 70 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

8.5. Юридик затларга призлар Конкурс йомгаклары турында беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында, редакцияне җиңүче дип игълан иткәннән соң Агентлык җитәкчелегенә язылган рәсми хатта күрсәтелгән исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

8.6. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү көннәрендә аларның туклану һәм яшәү шартлары оештыручы исәбеннән түләнә. Җиңүчеләрне бүләкләү датасы өстәмә хәбәр ителә.

## 9. Аерым шартлар

9.1. Оештыручылар түбәндәгеләргә хокуклы:

- әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән очраклардан, шулай ук бәхәсле очраклардан тыш, Конкурста катнашучылар белән язмача йә башка төрле элемтәләргә кермәскә;
- эшләрне тапшыру срогының беренче яртысында Россия Федерациясе законнары таләпләрен (РФ ГК 1058 ст.) үтәп, Конкурсны туктатырга яки әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, бу хакта Агентлыкның рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) “Яңалыклар” бүлегендә һәм Министрлыкның рәсми

сайтында (http://mvd.tatarstan.ru) “Яңалыклар” бүлегендә тиешле мәгълүмат урнаштырып, Катнашучыларга хәбәр итәргә.

9.2. Конкурсның максатларын һәм бурычларын үзгәртүдән тыш, калган барлык шартларына үзгәрешләр кертергә мөмкин.

9.3. Конкурс шартлары үзгәрү турында хәбәрнамә алганнан соң, Конкурста катнашучы эшләрне элек билгеләнгән шартларда кабул итүне яисә кертелгән үзгәрешләрне гамәлдә түгел дип тануны таләп итә алмый. Аның эшне Конкурсның яңа шартларына туры китереп үзгәртүе алга таба конкурста катнашырга мөмкинлек бирә.

9.4. Авторның Конкурс шартлары үзгәрүен яисә Конкурсның туктатылуын җитди сәбәпләр аркасында белмәве игътибарга алынмый.

2019 елда журналистларның
“Многоликая Россия”
XII гомумроссия
конкурсын үткәрү турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта

**2019 елда журналистларның**
**“Многоликая Россия” XII гомумроссия конкурсында катнашу өчен**
**АНКЕТА-ГАРИЗА**

**Гариза бирүче (ММЧ исеме)**

______________________________________________

**ММЧ җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме**

______________________________________________

**Элемтә өчен телефон**

______________________________________________

**Материалның чыгу датасы**

______________________________________________

**Номинация**

______________________________________________

**Конкурска җибәрелгән эшнең исеме**

______________________________________________

**Кыскача эчтәлеге**

______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________

**Адрес**

______________________________________________

**Телефон/факс**

______________________________________________

**e-mail**

___________________________________________________________________________

Журналистларның “Многоликая Россия” XII гомумроссия ачык конкурсына җибәрелгән конкурс эшләренең _________ (оешма исеме) милке булуын раслыйбыз. Конкурста катнашу авторлык хокукын яисә өченче затларның нинди дә булса башка хокукларын бозмый. Конкурска җибәрелгән эшләрдән файдалана алу мөмкинлегенә карата өченче затлардан хокукый дәгъвалар кергән очракта, аларны _________ (оешма исеме) белдерергә кирәк.

**Гариза биргән ММЧ җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча)___________________________________**

**(гариза биргән ММЧ җитәкчесенең мөһер белән таныкланган (булган очракта) имзасы**